**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Вязовка авыл җирлеге составына керүче Коногоровка авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2022 елның 29 октябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Коногоровка авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның җыены

Карар итте:

1. 2022 нче елда, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм тыл хезмәтчәннәреннән тыш, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Коногоровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны Коногоровка авылындагы зиратны төзекләндерүгә юнәлдерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Вязовка авыл җирлеге башлыгы** **А. Г. Томский**